СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2022 елның 3 феврале № 16/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 30 мартындагы 26/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары, Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 30 мартындагы 26/1 номерлы (11.05.2018 № 27/3, 28.09.2020 № 1/5 редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **5 нче кушымтаның** «МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТНЕҢ АЕРЫМ ШАРТЛАРЫ ӨЧЕН ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДКА АЙЛЫК ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ ҺӘМ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ТӘРТИБЕ» **беренче абзацында** «(авырлык, киеренкелек, хезмәттәге югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) **7 нче кушымтаның** «МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННЫҢ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ АЙЛЫК АКЧАЛАТА БҮЛӘКЛӘҮНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ КҮЛӘМНӘРЕ ҺӘМ ТӘРТИБЕ» **абзацына** «, җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп оештырганда, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең элек биләгән вазыйфасыннан түбәнрәк вазыйфаи окладлы вазыйфасына билгеләгән очрактан башка, бу вакытта акчалата бүләкләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата күләмен элек биләгән вазыйфасының акчалата түләү күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла» сүзләрен өстәргә;

3) **11 нче кушымтаның** «ТӨП ХЕЗМӘТ БУРЫЧЛАРЫНА ХОКУКЫЙ АКТЛАРГА ҺӘМ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫНА ХОКУКЫЙ ЭКСПЕРТИЗА ҮТКӘРҮ, ХОКУКЫЙ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫН ӘЗЕРЛӘҮ ҺӘМ РЕДАКЦИЯЛӘҮ ҺӘМ АЛАРНЫ ЮРИСТ ЯКИ ЮГАРЫ ЮРИДИК БЕЛЕМГӘ ИЯ БУЛГАН БАШКАРУЧЫ СЫЙФАТЫНДА ВИЗАЛАУ (ЮРИДИК ЭШ ӨЧЕН ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР) КЕРГӘН МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ АЙ САЕН БИРЕЛӘ ТОРГАН ТҮЛӘҮНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ КҮЛӘМНӘРЕ ҺӘМ ТӘРТИБЕ» **3 пунктын** төшереп калдырырга;

4) **12 нче кушымтада** «НОРМАЛАШТЫРЫЛМАГАН ХЕЗМӘТ КӨНЕ ШАРТЛАРЫНДА ЭШЛӘГӘН ӨЧЕН МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ АЙЛЫК КОМПЕНСАЦИЯ ТҮЛӘВЕН БИЛГЕЛӘҮ ҺӘМ ИСӘПЛӘҮ ТӘРТИБЕ»:

**1** һәм **2 пунктларны** түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен ай саен түләнә торган компенсация түләве вазыйфаи окладның 2 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә.

2. Нормалаштырылмаган хезмәт көне муниципаль хезмәтнең югары һәм төп вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр өчен билгеләнә. Муниципаль хезмәтнең башка төркемнәре вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр өчен нормалаштырылмаган хезмәт көне вазыйфаларның тиешле исемлеге һәм хезмәт шартнамәсе буенча муниципаль органның хезмәт тәртибе нигезендә билгеләнә.»;

**3 пунктны** төшереп калдырырга;

5) **14 нче кушымтада** «МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ ДӘҮЛӘТ СЕРЕН ТӘШКИЛ ИТҮЧЕ БЕЛЕШМӘЛӘР БЕЛӘН ЭШЛӘГӘН ӨЧЕН ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДКА ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ ҺӘМ ТӘРТИБЕ»:

**2 пунктны** түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Муниципаль хезмәттә дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен бирелә торган өстәмә түләү түбәндәге күләмнәрдә түләнә:

| Серлелек дәрәҗәсе | айлык өстәмә түләү күләме, %да |
|---|---|
| «Аеруча мөһим» серлелек дәрәҗәсенә ия булган | 50-70 |

| | |
|---|---|
| белешмәләр белән эшләгән өчен | |
| «Бөтенләй яшерен» серлелек дәрәҗәсенә ия булган белешмәләр белән эшләгән өчен | 30-50 |
| Серлелек дәрәҗәсе булган мәгълүматлар белән эшләү өчен «яшерен» рөхсәт рәсмиләштергәндә тикшерү чараларын үткәреп, | 10-15 |
| тикшерү чаралары үткәрмичә | 5 - 10 |
| Дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләрдә эш стажы өчен: | |
| 1 елдан алып 5 елга кадәр | 10 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 15 |
| 10 елдан һәм аннан күбрәк | 20.»; |

түбәндәге эчтәлектәге **3 пунктны өстәргә**:

«3. Күрсәтелгән өстәмәне алу хокукын бирә торган дәүләт серен яклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренең эш стажына дәүләт хакимиятенең башка органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның дәүләт серен яклау буенча структур бүлекчәләрендә эшләү вакыты кертелә.»;

6) **18 нче кушымтада** «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ФОНДЫН ФОРМАЛАШТЫРУ ТӘРТИБЕ»:

**3 пунктчада** «(катлаулылык, киеренкелек, хезмәттәге югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле **7 пунктча өстәргә**:

«7) нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен ай саен түләнә торган компенсация түләве, юридик эш өчен өстәмә түләү һәм профильле гыйльми дәрәҗә өчен вазыйфаи окладка ай саен түләнә торган өстәмә түләү - вазыйфаи окладларның 2,5 процентыннан артмаган күләмдә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы,Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров